КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 май

г.Казань

№ 414

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схеманы раслау турында» 2018 ел, 13 март, 149 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схемага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схеманы раслау турында» 2018 ел, 13 март, 149 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 14 май, 391 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасында калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә территориаль схемага, 10 бүлекнең 10.4 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«**10.4. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә иң чик тарифларны исәпләү**

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә иң чик тарифларның түбәндәге төрләре җайга салынырга тиеш:

каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә бердәм тариф;

каты коммуналь калдыкларын эшкәртү тарифы;
каты коммуналь калдыкларын зарарсызландыру тарифы;
каты коммуналь калдыкларын күмү тарифы;
энергетик утильләштерүгә тариф.

Тарифлар Россия Федерациясе субъектының тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге башкарма хакимият органы йә, Россия Федерациясе субъекты законы белән тиешле вәкаләтләр тапшырылган очракта, тарифларны җайга салуны гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә, шул ук вакытта алар җитештерү һәм инвестиция программаларын тормышка ашыруга икътисадый нигезләнгән чыгымнарны компенсацияләргә һәм агымдагы эшчәнлек табышлылыгың һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган инвестицияләнгән капиталның икътисадый нигезләнгән дәрәҗәсен тәэмин итәргә тиеш.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә бердәм тарифны исәпләү, юридик затка төбәк операторы статусы бирелгән һәм аның эшчәнлек зонасы конкурс буенча сайлап алу нигезендә билгеләгәннән соң, субъектның вәкаләтле башкарма хакимият органнары тарафыннан башкарыла, конкурс буенча сайлап алу Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле башкарма хакимият органнары тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтле башкарма хакимият органнары тарафыннан каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында» 2016 елның 5 сентябрендәге 881 номерлы карары нигезендә үткәрелә.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә бердәм тарифны исәпләү Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя билгеләү нигезләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә тарифларны җайга салу кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртип һәм Монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Каты коммуналь калдыклары белән эш итү өлкәсендәге мәгълүмат, шул исәптән тарифлар һәм төбәк операторы турындагы белешмәләр ачык булырга һәм операторларның һәм (яки) Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтларында урнаштырылырга тиеш. Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары белән расланган.

Эшчәнлек зоналарының һәрберсе өчен төбәк операторыларының бердәм тарифының фаразланган мәгънәләре 10.4.1 һәм 10.4.2 нче таблицаларда китерелгән.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә иң чик тарифларның фаразланган мәгънәләре кирәкле тулаем керемгә, шул исәптән тарифларны билгеләгәндә исәпкә алынмаган законнарга үзгәреш кертүгә бәйле рәвештә һәм

чыгымнарны һәм алынып бетмәгән керемнәрне каплауга бәйле рәвештә, шулай ук нигезсез алынган керемнәрне төшереп калдыруга бәйле рәвештә төзәтмәләр кертүне исәпкә алмый.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә иң чик тарифлар Татарстан Республикасы тарифларын җайга салу органы тарафыннан раслана. Территориаль схемада китерелгән тарифларның мәгънәләре фараз булып тора һәм белешмә өчен китерелгән.

10.4.1 нче таблица

Төбәк операторыларның бердәм тарифының фаразланган мәгънәләре

(бер тоннага сум, өстәлгән бәягә салымсыз)

| Төбәк операторы эшчәнлеге зонасы | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Көнбатыш | 3 209 | 3 559 | 6 410 | 6 574 | 6 745 | 6 929 | 7 102 | 7 278 | 7 447 |
| Көнчыгыш | 3 016 | 3 644 | 6 937 | 7 164 | 7 393 | 7 664 | 7 867 | 8 064 | 8 275 |
| Уртача мәгънә | 3 120 | 3 598 | 6 653 | 6 846 | 7 043 | 7 268 | 7 454 | 7 640 | 7 829 |

10.4.2 нче таблица

Төбәк операторыларның бердәм тарифының фаразланган мәгънәләре

(1 куб.метрга сум, өстәлгән бәягә салымсыз)*

| Төбәк операторы эшчәнлеге зонасы | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Көнбатыш | 416 | 461 | 831 | 852 | 874 | 898 | 921 | 943 | 965 |
| Көнчыгыш | 391 | 472 | 899 | 929 | 958 | 993 | 1 020 | 1 045 | 1 073 |
| Уртача мәгънә | 404 | 466 | 862 | 887 | 913 | 942 | 966 | 990 | 1 015 |

*Исәпләү, уртача тыгызлыкны 1 куб.метрга 0,1296185 тонна күләмендә кулланып, 1 тоннага фаразланган тариф мәгънәләреннән күчерү юлы белән башкарылды.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин